МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.11.2014 г. Казань № 6575/14

Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» нигезендә боерык бирәм:

1. Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары С.В. Гыйниятуллинага йөкләргә

Министр вазифаларын башкаручы И. Р. Мөхәммәтов

**Татарстан Республикасы**
**Мәгариф һәм фән министрлыгы**
**18.11.2014 6575/14 номерлы**
**боерыгы белән расланды**

# Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсус торак фондыннан торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсус торак фондының торак урыны белән тәэмин итүгә мохтаҗлар сыйфатында исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган, махсуслаштырылган торак фондының торак урыны бирелүгә мохтаҗ затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский ур., 3, 207 кабинет.

Министрлыкның кабул итү графигы: кышкы вакытта 1 октябрьдән 31 мартка кадәр атна саен, һәр сишәмбе көнне 9-00 дән 18-00 гә кадәр, төшке аш 12-30 дан 13-30 га кадәр; җәйге вакытта 1 апрельдән 30 сентябрьгә кадәр, һәр сишәмбе көнне 8-00 дән 17-00 гә кадәр, төшке аш 12-00 дән 13-00 гә кадәр.

«Ирек мәйданы», «КАИ», «Үзәк стадион» тукталышына кадәр җәмәгать транспорты белән килү мөмкин.

Пропуск һәм (яки) шәхесне раслый торган документ буенча узарга.

1.3.2. Белешмә өчен телефоннар: 294-95-67, 294-95-66.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты адресы (алга таба - «Интернет» челтәре):http://www.mon.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезёмәте турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.mon.tatar.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

2) министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

3) язма рәвештә (шул исәптән электрон адреска электрон документ рәвешендә: mon@tatar.ru) министрлыкка мөрәҗәгать иткәндә;

4) гариза бирүчеләр белән эшләү урыннарында министрлык биналарында урнашкан визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша.

1.3.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында идарә итүнең автоматлаштырылган системалары һәм мәгълүмати куркынычсызлык бүлеге белгече тарафыннан урнаштырыла (http://www.mon.tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү:

Россия Федерациясе Торак кодексында 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы (алга таба - РФ ТК) (РФ кануннары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (I өлеш) 14 ст.

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә гарантияләре турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 159-ФЗ номерлы Федераль закон) (РФ кануннары җыентыгы, 23.12.1996, № 52, 5880 ст.);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ кануннары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (РФ кануннары җыентыгы, 06.02.2006, № 6, 702 ст.);

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы) (Татарстан Республикасы, № 9, 18.01.2013, Ватаным Татарстан, № 10, 19.01.2013, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 1, 8 ст.);

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм Татарстан Республикасы Законының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба - 312 номерлы Татарстан Республикасы МКК) гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 04 маендагы 312 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре җыентыгы һәм

республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары, 21.05.2013, № 37, 1106 ст.);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны, махсуслаштырылган торак фондының торак урыннары белән тәэмин итүне оештыру турында» 2014 елның 17 мартындагы 1367/14 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокукый мәгълүмат рәсми сайты http://pravo.tatarstan.ru, 26.03.2014) нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандарты

| Стандартка карата таләп, дәүләт хезмәте күрсәтелү аталышы | Стандарт таләбе эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте аталышы | Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны (алга таба - ятим балалар, ятим бала) махсуслаштырылган торак фондының торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте | 8 ст. ФЗ, 21.12.1996 ел, № 159 ФЗ;<br>ст. 2 ТРЗ, 12.01.2013 ел, № 8-ТРЗ |
| 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның аталышы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ТР Министрлар кабинетының 312 номерлы карары |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе | ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсуслаштырылган торак фондының торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак исемлеккә кертү турында карар (алга таба - Исемлек);<br>исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар. | ст. 2 п. 11 ТРЗ 12.01.2013 ел, № 8-ТРЗ |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы | Ятим баланы исемлеккә кертү яки кертмәү турында карар, гаризаны теркәгән көннән алып 23 эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге регламентның 2.5, 2.6 пунктларында күрсәтелгән документларны алганнан соң да, элек биләгән торак биналарда яшәү мөмкинлеге яки мөмкин булмавы турында бәяләмә белән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, | ст. 2 п.11 ТРЗ 12.01.2013 ел, № 8-ТРЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | почта аша тиешле документларны тапшырган гражданга җибәрелә яисә ятим баланы исемлеккә кертүне кире кагу турында карар кабул итүне раслый торган документ имза куйдырып тапшырыла. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури булган хезмәтләрнең һәм мәҗбүри булган документларның тулы исемлеге | 1) Исемлеккә кертү турында гариза;<br>2) граждан шәхесен раслый торган паспорт яисә башка документ күчермәсе;<br>3) балигъ булмаган гражданның законлы вәкиленең шәхесен һәм аның вәкаләтләрен раслый торган документ яки балигъ булмаган гражданны тулысынча эшкә сәләтле түгел (эмансипацияләнгән) дип игълан итүне раслый торган документ (балигъ булмаган гражданның законлы вәкиле яки 18 яшькә кадәрге граждан мөрәҗәгатендә);<br>4) күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алучы орган белешмәсе, ятим баланың Россия Федерациясе территориясендә милек хокукында торак урыннары булу яисә булмавы турында (социаль найм шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары яисә торак урынын яллаучы гаилә әгъзалары яки торак урыннар милекчеләре булып тормаучы ятим балалар тарафыннан бирелә); | ст. 2 п. 4-5 ТРЗ 12.01.2013 ел, №8-ТРЗ<br>5 |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) 159-ФЗ номерлы Федераль законда һәм 12.01.2013 № 8-ТРЗ номерлы Законда каралганча, үзләре биләгән торак бинада яшәү мөмкин булмавын раслый торган документлар. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1) күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан Россия Федерациясе территориясендә күчемсез мөлкәт объектларына мөрәҗәгать итүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга хокуклары турында өземтәләр.<br>1) күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән алыш-биреш килешүләреннән гариза бирүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга күчемсез мөлкәт объектларына хокукларның күчүе турында өземтәләр.<br>2) күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган).<br>3) гражданның Татарстан Республикасы буенча техник инвентаризация оешмасы тарафыннан бирелгән торак урыннары булу (булмау) турында белешмә. | ст. 2 п. 6 ТРЗ 12.01.2013 ел, № 8-ТРЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда аларны килештерү дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителә торган һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәтен килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Тиешле булмаган зат тарафыннан документлар тапшыру (гариза бирүче булмаган һәм дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчене тәкъдим итү хокукына нотариаль рәсмиләштерелгән ышанычнамәсе булмаган зат).<br>2. Гаризада һәм (яисә) тәкъдим ителгән документларда ассызыклаулар, өстәмәләр, сызылган сүзләр, төзәтмәләр булу. Тексты укып булмый торган таләп ителгән документларны тапшыру | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр<br>1. ятим бала 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның берсенә дә кагылмый;<br>2. мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиеш документлар тапшырылмаган яисә тулы күләмдә тапшырылмаган; | ст.2 п. 9 ТРЗ 12.01.2013 ел, № 8-ТРЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. дәүләт хакимияте органының йә ведомствоара оешманың дәүләт хакимияте органына караган җавабы, әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган булса, мондый органнар яки оешмалар карамагында мондый документ яки мәгълүмат булмау тиешле гражданнарның исемлеккә кертелү хокукын раслый торган очраклардан тыш, сорала торган документ һәм (яки) мәгълүматның булмавын раслый;<br>4. тапшырылган документларда ятим бала турында дөрес булмаган мәгълүматлар бар. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләүне алу тәртибе, күләме һәм алу нигезләре, мондый түләүнең күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында сорату юллаганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Мөрәҗәгать итүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмаска тиеш. Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы | Гариза килеп ирешкән көнне | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү тиешле күрсәткечләр белән җиһазландырылган биналарда башкарыла.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларны әлеге максатлар өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарда - янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән;<br>документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар;<br>мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган урыннарда кабул итәләр | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге һәм аның сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>1) җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада кабул ителә торган биналарның урнашуы;<br>2) гариза бирүчеләрдән документлар кабул ителә торган белгечләрнең, шулай ук бүлмәләрнең кирәкле санда булуы; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 3) дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында "Интернет" челтәрендәге мәгълүмат стендларында, мәгълүмат ресурсларында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләрне үтәү тора:<br><br>1) Документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | Гариза һәм документларның күчермәләре электрон рәвештә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы аша түбәндәге адрес буенча җибәрелергә мөмкин: http://uslugi.tatar.ru/ соңыннан карар кабул иткәндә документларның төп нөсхәләрен күрсәтү кирәк булачак | |

3. **Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) башкару үзенчәлекләре**

3.1 Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гариза бирүчене кабул итү, документлар кабул итү;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм җибәрү;

4) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы торак комиссиясе утырышында документларны карау (алга таба – Комиссия);

5) ятим балаларны исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту турында карар әзерләү;

6) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү;

7) гариза бирүчегә нигезләре булганда дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат юллау.

3.1.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада тәкъдим ителгән.

3.2. Гариза тапшыручыга консультация бирү.

Гариза тапшыручы шәхсән, телефон аша, электрон почта (http://www.mon.tatar.ru) аша һәм (яисә) хат белән дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация бирү өчен яшәү урыны буенча министрлыкка яки опека һәм попечительлек органына мөрәҗәгать итә.

Министрлык хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә. Министрлык хезмәткәре гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү предметына консультация бирә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бланкын бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документлар исемлегенең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация, искәрмәләр.

Гариза бирүчене кабул итү, документлар кабул итү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче турыдан-туры яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын кулланып яисә кәгазь формада күрсәтелгән документлар белән Министрлыкның опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (алга таба - бүлек) гариза бирә.

3.3.2. Гражданнарны кабул итүне алып баручы бүлек хезмәткәре, әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә;

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булмаганда, белгеч гаризаны документлар белән кабул итә һәм теркәп бара.

Мөрәҗәгать итүчегә документларны аларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, шулай ук ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алыначак документлар исемлеген күрсәтеп алуга расписка бирелә.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, бүлек белгече гаризаны теркәү өчен киртәләр булуы турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлегенә язмача аңлатма биреп, документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гражданны кабул итү көнендә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гражданнарны кабул итү журналында язылу яки документлар кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итү.

3.3.2. Бүлек хезмәткәре әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуын тикшерә.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек хезмәткәре әлеге Регламентның 3.7.2 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүче биргән документлардагы белешмәләрне тикшерү эшен оештыра һәм Комиссия каравына җибәрә. Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза кергән көннән алып 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.



Процедураларның нәтиҗәсе: документларны тикшерү һәм Комиссияне карауга җибәрү турында карар кабул итү.

Ведомствоара соратуларны формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек хезмәткәре электрон формада ведомствоара электрон бәйләнеш системасы чаралары буенча түбәндәгеләрне сорап җибәрә:



күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан Россия Федерациясе территориясендә күчемсез мөлкәт объектларына мөрәҗәгать итүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга хокуклары турында өземтәләр;

күчемсез милек объектларына хокукларны мөрәҗәгать итүчегә, аның гаилә әгъзаларына һәм алар белән бергә теркәлгән барлык гражданнарга күчерү турында күчемсез милек һәм аның белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр;

күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән алыш-бирешләрдән өземтәләр (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында халыкка җиткерелергә тиешле белешмәләрне үз эченә ала);

гражданның Татарстан Республикасы буенча техник инвентаризация оешмасы тарафыннан бирелгән торак урыннары булу (булмау) турында белешмә.

Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе; мәгълүмат тәкъдим итү турында сораулар җибәрү.

3.4.2. Ведомствоара электрон багланышлар системасы аша кергән белешмәләр белән тәэмин итүче белгеч министрлыкка сорала торган документлар (белешмәләр) бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар ведомствоара сорау һәм мәгълүмат бирә торган органга яисә оешмага килеп ирешкән көннән алып биш көн эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара соратуга җавапны әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

3.5. Комиссия утырышында документларны карау.

3.5.1. Министрлык хезмәткәре ятим балаларның шәхси эшләрен рәсмиләштерә (барлык документларны аерым папкага җыя) һәм Комиссия каравына җибәрә.

3.5.2. Комиссия сәркәтибе килеп ирешкән документларны өйрәнә, Комиссия утырышы көнен билгели һәм Комиссия әгъзаларына хәбәр итә. Торак комиссиясе аена бер тапкыр уздырыла.

3.5.3. Комиссия үз утырышында шәхси эшләрне карый һәм ятим балаларны исемлеккә кертү турында яки кертүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.5.4. Комиссия сәркәтибе Комиссия карарын беркетмә рәвешендә (бер нөсхә) формалаштыра һәм имза кую өчен Комиссия әгъзаларына тапшыра. Комиссия әгъзалары беркетмәгә кул куя һәм аны Комиссия сәркәтибенә җибәрә. Комиссия сәркәтибе комиссия протоколын Бүлек белгеченә шәхси эш белән җибәрә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән Процедура сорауларга җавап килгәннән соң 2 көн эчендә башкарыла.

Комиссиянең көтү вакыты дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: Министрлык хезмәткәренә җибәрелгән беркетмә һәм шәхси эш.

3.6. Дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү.

3.6.1. Министрлык хезмәткәре комиссия тарафыннан ятим балаларны исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту карар кабул ителгән очракта, ятим балаларны исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту турында хат проектын әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры урынбасарына килештерүгә җибәрә.

3.6.2. Министр урынбасары хатка кул куя һәм Министрлык хезмәткәренә җибәрә. Бу пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә башкарыла. Процедураларның нәтиҗәсе: министрлык хезмәткәренә җибәрелгән имзаланган хат.

3.7. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү.

3.7.1. Ятим балаларны исемлеккә кертү турында Карар кабул ителгән очракта, Министрлык хезмәткәре гариза бирүче турында мәгълүматларны белешмәләр базасына кертә (ятим балаларның бердәм исемлеген төзи)

3.7.2. Ятим балаларны исемлеккә кертүдән баш тарткан очракта, исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы хат гариза бирүчегә почта аша җибәрелә яки имза куйдырылып бирелә.

Министрлык хезмәткәре барлык документларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара һәм карарның шикаять бирү тәртибен аңлата.

3.7.3. Ятим балаларны исемлеккә керткән очракта, исемлеккә кертү турындагы хат гариза бирүчегә почта аша җибәрелә яки имза астында бирелә.

Әлеге пункт тарафыннан билгеләнгән процедуралар 23 эш көне эчендә, әмма 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча, гариза тапшырылганнан соң башкарыла. Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен бирү.

3.8. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - күпфункцияле үзәк) аша дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.8.1. Күп функцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтелми.

**4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контроольдә тоту тәртибе һәм формалары**

4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулы һәм сыйфатын тикшереп тору гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларын үтәүне тикшерүне, карарлар кабул итүне һәм Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләре булган мөрәҗәгатьләргә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләр:

- дәүләт хезмәте күрсәтү документлары проектларына хокукый экспертиза үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе - проектларны визалау;

-Эш башкаруны алып баруны билгеләнгән тәртиптә тикшерүләр;

- дәүләт хезмәтен күрсәтү процедураларының үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә (комплекслы тикшерүләргә) бәйле барлык мәсьәләләр яисә мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә һәм карар кабул иткәндә гамәлләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатларында министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүне даими тикшереп тору дәүләт хезмәтен күрсәтү эшен оештыруда җаваплы белгеч, бүлек башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм вазифаи регламентлар турындагы нигезләмәләр белән билгеләнә.Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылган очракта, гаепле затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында тикшермәгән өчен җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

**5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының, шулай ук дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе**

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы министрлык хезмәткәрләренең гамәлләренең (гамәл кылмавының) судка кадәр тәртибендә Татарстан Республикасы Министрлыгына яисә Министрлар Кабинетына шикаять бирү хокукына ия.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда: гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризасын теркәү срогын бозу;

дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын бозу; дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган гариза бирүчедән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

әгәр баш тарту нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүгә дәүләт хезмәте күрсәткәндә таләп итү;

министрлыкның вазифаи заты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять кәгазьдә яки электрон формада язмача бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын кулланып җибәрелергә мөмкин (http://mon.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatar.ru/), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (функцияләр) (http://www.gosuslugi.ru/), шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты-теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган вазифаи заты гариза бирүчедән документлар кабул итүдә яки җибәрелгән хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять биргән очракта-аны теркәү көненнән алып биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның яисә дәүләт хезмәткәренең вазифаи заты, аларның карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) шикаять ителә торган орган исеме;

2) мөрәҗәгать итүченең - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турындагы мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче - юридик затның урнашу урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номеры), электрон почта адресы (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазифаи затның яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәл кылмавы (гамәл кылмавы) белән килешми торган дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять аны тапшырган дәүләт хезмәте алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча министрлык түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән ялгышларны, хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка формаларда канәгатьләндерә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Әлеге Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә мөрәҗәгать итүчегә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

**Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган
балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан
мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны
махсус торак фондыннан торак урыны бирелүгә мохтаҗ
буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта**

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы һәм аны күрсәтүне агымдагы контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге**

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Бүлек башлыгы | (8-843) 294-95-66 | Zulfiya.Musabirova(a)@tatar.ru |
| Бүлек белгече | (8-843) 294-95-67 | Natalya.Kadyrmetova@tatar.ru |

**Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны махсус торак фондыннан торак урыны бирелүгә мохтаҗ буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта**

**Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы**

Гариза тапшыручы

Опека һәм попечительлек органы хезмәткәре консультациясе

мөрәҗәгать итүчене кабул итү, документлар кабул итү (1 эш көне)

документлар кабул итүдән баш тарту өчен бер эш көне эчендә нигезләүләрне ачыклау

Документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмау, гаризаны 1 эш көне дәвамында теркәү

Документлар 1 эш көне дәвамында

Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар барлыгы турында шәхсән үзе хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язма рәвештә аңлатып, документларны 3 эш көне эчендә кайтара.

Баш тарту өчен нигезләр булмаганда, ведомствоара багланышлар кысаларында кирәкле соратуларны җибәрә (5 эш көне дәвамында)

Баш тарту өчен нигез булганда, 1 эш көне дәвамында баш тарту турында хат әзерли

2 эш көне дәвамында Комиссиягә карау өчен алып чыга

2 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә ятим баланы Исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту турында карар бирү

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен 23 эш көне эчендә, әмма 30 календарь көннән дә соңга калмыйча бирү